**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Уразаевского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Н.Бадертдинова , д. 35, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района РТ
423303

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авылы җирлеге**
**башлыгы**

Н.Бадертдинов урамы, 35,Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы ТР
423303

Тел./факс(885592)43-5-55; E-mail:Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октябрь 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында, Уразай авылында Энгельс урамы 1 нче йорттан 131 нче йортка, Гараж урамы 1 нче йорттан 4 нче йортка,Садовая урамы 2 нче йорттан 4 нче йортка кадэр теркэлгэн һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 08 ноябрендэ 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында, Уразай авылында Яшьлэр урамы 1/1 нче йорттан 70 нчы йортка, Подгорная урамы 1 нче йорттан 32 нчы йортка,Речная урамы 1 нче йорттан 23А нче йортка, Н.Бадертдинов 1 нче йорттан 36А нчы йортка кадэр теркэлгэн һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 08 ноябрендэ 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргэ:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында үзара салым кертү мэсьэлэсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты.;

- гражданнар жыенының беренче этабын уздыру вакыты-2022 елның 08 ноябрендә 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар жыенының икенче этабын уздыру вакыты-2022 елның 08 ноябрендә 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

-гражданнар жыенынын беренче, икенче этабларын уздыру урыны-Уразай авылы, Энгельс урамы, 63 нче йорт, Уразай авыл Мэдэният йорты залы;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 29 октябереннән дә соңга калмыйча гражданнарга Уразай авылы, Н.Бадертдинов урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетында мәгълумат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә.;

-Уразай торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәучеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Уразай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарнын җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлту белән килешэсезме:

- 1941-45 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга багышланган һәйкәлне ремонтлау . ;

- авыл җирлеге юлларын кардан чистарту;

- авыл җирлеге территорияләрен чистарту( чүп үләне кисү, агачларны кисү һәм чүп җыю);

- халык өчен мәдәни чаралар үткәрү (Җиңү көне -9 Май, Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел);

-Беларус 82 тракторына запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы түләү керә;

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Уразай авылы, Н.Бадертдинов ур., 35 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башлык А.М.Шарифуллина